«Раслыйм»
Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
«Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегенең
Җир биләмәләреннән файдалану һәм
Төзелеш кагыйдәләре комиссия рәисе

_______________________И.Ф. Рәхимов

№ 8
2020 елның 2 сентябре

Территорияне межалау һәм җир кишәрлегеннән шартлы рәвештә рөхсәт ителгән файдалануга рөхсәт бирү проекты буенча ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында

**БӘЯЛӘМӘ**

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгының «Ачык тыңлауларны билгеләү турында» гы 2020 елның 30 июнендәге 19 номерлы һәм 2020 елның 5 августындагы 21 номерлы карары белән билгеләнгән ачык тыңлаулар 2020 елның 26 августында 10.00 сәгатьтә Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының зур залында түбәндәге адрес буенча узды: Татарстан Республикасы, Чистай муниципаль районы, Чистай шәһәре, Бебель урамы, 129 нчы йорт.

Территорияне межалау һәм 2020 елның 2 сентябрендәге 8 номерлы җир кишәрлегеннән шартлы рөхсәт ителгән файдалануга рөхсәт бирү проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү беркетмәсе.

**Ачык тыңлаулар предметы:**

1. «Чистай БТИ» ҖЧҖ мөрәҗәгате буенча Татарстан Республикасының Чистай шәһәре Учхоз поселогы чикләрендә территорияне межалау проектын карау турында.

Комиссия тарафыннан Татарстан Республикасының Чистай шәһәре Учхоз поселогы чикләрендә территорияне межалау проектын хуплау турында карар кабул ителде.

2. гр. Хәсәнова Алсу Әсхәт кызы мөрәҗәгате буенча, кадастр номеры 16:54:160311:11, мәйданы 469,2 кв.м. булган, түбәндәге адрес буенча урнашкан җир кишәрлегеннән шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча: Татарстан Республикасы, Чистай муниципаль районы, Чистай шәһәре, К.Маркс урамы, 127 йорт - «Кибетләр» ИТ-4 зонасында «Транспорт инфраструктурасы объектларын урнаштыру зонасы».

**Карар ителде:**

1. Татарстан Республикасы Чистай шәһәре Учхоз поселогы чикләрендә территорияне межалау проекты буенча ачык тыңлауларны булган дип санарга.

2. Татарстан Республикасының Чистай шәһәре Учхоз поселогы территориясен межалау проектын хупларга.

3. гр. Хәсәнова Алсу Әсхәт кызына, кадастр номеры 16:54:160311:11 булган җир кишәрлегенә карата «Азык-төлек сәүдәсе предприятиеләре өчен санитар кагыйдәләр» СанПиН 2.3.5.021-94 таләпләрен үтәүне тәкъдим итәргә.

4. гр. Хәсәнова Алсу Әсхәт кызына, кадастр номеры 16:54:160311:11, мәйданы 469,2 кв.м. булган, түбәндәге адрес буенча урнашкан җир кишәрлегеннән шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт итәргә: Татарстан Республикасы, Чистай муниципаль районы, Чистай шәһәре, К.Маркс урамы, 127 йорт - «Кибетләр» ИТ-4 зонасында «Транспорт инфраструктурасы объектларын урнаштыру зонасы».

5. Әлеге бәяләмәне Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырырга һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Комиссия сәркатибе: ______________________Бибишев М.Р.